ГЛАВА ОКТЯБРЬСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Ул. Декабристов, д.35 а, с. Печищи,
422592

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ОКТЯБРЬСКИЙ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

Декабристлар ур., 35 нче йорт, Печищи авылы,
422592

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

ПОСТАНОВЛЕНИЕ　　　　　　　　　　КАРАР

02.10.2023　　　　　　　　　　04

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

пос. Октябрьский

**Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлегенең Яңа-Болгар авылында гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003нче елның 6нчы октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56нчы статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35нче статьясына, Югары Ослан муниципаль районы Октябрьский авыл җирлеге Уставынаың 24 ст. туры китереп,

КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлегенең Яңа-Болгар авылы гражданнары арасында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын 2023 елның 14 октябренә билгеләргә.

2. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

   «Сез 2024 елда Югары Ослан муниципаль районы Октябрьский авыл җирлегенең Яңа-Болгар авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы:

   - Су алу җайланмасын төзекләндерү

   «ӘЙЕ　　　　　　　　　　«ЮК»

3. Яңа-Болгар ав., Мәктәп ур., 1А йорт адресы буенча мәчет бинасы территориясендә гражданнар җыенын 10.00 сәгатьтә уздырырга.

4. Октябрьский авыл җирлегенең Башкарма комитетын гражданнар җыенын оештыручы итеп билгеләргә.

5. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында, шулай ук мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
Октябрьский авыл җирлеге башлыгы　　　　　　　　Ш. Р. Азизов